**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА
СТЕПНООЗЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423009, с. Степное Озеро, ул. Школьная,
дом 23, телефон:8(84345) 4-63-34

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**БИКҮЛЕ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ НУРЛАТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

423009, Бикүле авылы, Мәктәп ур.,
23 йорт, телефон:8(84345) 4-63-34

ОГРН 1021605352438,ОКПО 04312541, ОКАТО 92246880000,
ИНН/ КПП 1632001635/163201001,ОКТМО 92646480

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**« 02 » ноябрь 2022 ел** **№ 1**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлегенең Бикүле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2022 елның 14 ноябрендә 09 сәгать 00 минутта Мәктәп урамы буенча 19нчы йорт янында Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлегенең Бикүле авылындаТукай, Мәктәп урамы, Дружба урамы, Ленин урамы буенча, М. Җәлил урамы буенча 23-51, № 52-62 йортларда яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2022 елның 14 ноябрендә 10 сәгать 00 Ш. Камал урамы, 2 нче йорт янында Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлегенең Бикүле авылында Гагарин ур., Ш. Камал ур., Шоссе, Яшел урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2022 елның 14 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта М.Җәлил урамы буенча 21нче йорт янында Нурлат муниципаль районы Бикүле авылында М. Җәлил урамы буенча 1-21, 2-50 нче йортларда, Тихая, Һ. Такташ урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. Бикүле авылында яшәүчеләр исемлеген гражданнар җыенын уздыру өчен сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

5. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлегенең Бикүле авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, балачак инвалидларыннан, 1 гр инвалидлардан тыш, 2023 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Авыл эчендәге юлларны ремонтлау (грунт катыш таш өслеген күтәрү, вак таш җәю);
- Су белән тәэмин итү чыганакларын норматив хәлгә китерү;
- Парк зонасын төзекләндерү (стадион);
- Күперне ремонтлау;
- Янгын сүндерү машинасы тора торган боксны җылыту буенча чаралар үткәрү;

«РИЗА» «КАРШЫ»

8. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтына http://nurlat.tatarstan.ru урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Бикүле авыл җирлеге башлыгы А.М. Шакирова